ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.10.2021 с. Шеланга 07

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең
Нариман авылында гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 19 нчы ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Нариман авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Нариман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 нче елда 650 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Нариман авылында юлларны төзекләндерү һәм ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Нариман авылы, Центральная урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров